КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 апрель г.Казань № 509

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турында» 2012 ел, 20 февраль, 135 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 29 май, 454 нче; 2019 ел, 23 ноябрь, 1073 нче; 2021 ел, 12 февраль, 75 нче; 2022 ел, 17 май, 457 нче; 2022 ел, 7 июль, 651 нче; 2022 ел, 29 сентябрь, 1049 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсының конкурс комиссиясе составында:

комиссия составыннан А.А.Кондратьеваны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Софья Альфред кызы Мостафинаны кертергә;

Тимур Дамир улы Әхмәтвәлиевның вазыйфа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча)»;

әлеге карар белән расланган «Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Закон территориясе» еллык республика конкурсын үткәрү турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 20 апрель, 509 нчы карары редакциясендә)

«Муниципаль район һәм шәһәр округы территориясендә хокук тәртибен тәэмин итүгә керткән өлеш өчен» номинациясендә материалларны бәяләү критерийлары

| Т/с | Критерий исеме | Баллар саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Муниципаль район, шәһәр округы территориясендә җинаятьчелек һәм хокук тәртибе торышы (узган елның шул ук чоры белән чагыштырып, ел дәвамында кылынган җинаятьләр саны бәяләнә) | |
| 1.1. | Муниципаль район, шәһәр округы территориясендә җинаятьләр саны арту | – 5 |
| 1.2. | Муниципаль район, шәһәр округы территориясендә җинаятьләр саны кимү | + 5 |
| 2. | Муниципаль район, шәһәр округы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауда катнашу өчен төзелгән хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр, ирекле халык дружиналары саны | + 3<br>(һәр төзелгән һәм гамәлдәге берләшмә<br>һәм (яки) дружина өчен) |
| 3. | Тәртип саклау буенча җәмәгать пунктларын, участок полиция хезмәткәрләре өчен административ-торак комплексларны, участок полиция пунктларын матди-техник тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | |
| 3.1. | Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты, участок полиция хезмәткәрләре өчен административ-торак комплексы һәм участок полиция пункты бүлмәсенә капиталь ремонт ясау | + 1<br>(капиталь ремонт ясауга тотылган һәр 50,0 мең сум өчен) |
| 3.2. | Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты, участок полиция хезмәткәрләре өчен административ-торак комплексы һәм участок полиция пункты бүлмәсенә агымдагы ремонтны ясау | + 1<br>(агымдагы ремонт ясауга тотылган һәр 50,0 мең сум өчен) |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 3.3. | Тәртип саклау буенча җәмәгать пункты, участок полиция хезмәткәрләре өчен административ-торак комплексы һәм участок полиция пункты эшчәнлеге өчен кирәкле офис һәм көнкүреш техникасы, җиһаз һәм башка матди-техник чаралар сатып алу | + 1 (матди-техник тәэмин итүгә тотылган һәр 50,0 мең сум өчен) |
| 4. | Эчке эшләр органнарына матди-техник тәэмин итү мәсьәләләре буенча, шул исәптән эчке эшләр органнары биналарын һәм бүлмәләрен ремонтлауда булышлык күрсәтү | + 1 (матди-техник тәэмин итүгә тотылган һәр 50,0 мең сум өчен) |
| 5. | Эчке эшләр органнарына кадрлар туплауда булышлык күрсәтү | + 1 (бергә үткәрелгән һәр чара өчен) |
| 6. | Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренә социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыру | + 1 (социаль ярдәм чараларын гамәлгә ашыруга тотылган һәр 50,0 мең сум өчен) |

_______________________________